**Кукмара муниципаль районы**
**Мәмәшир авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**2022 елның «15» декабре** **№ 35**

**Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлегенең Тәмәй торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлегенең Тәмәй авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 25 ноябрендәге 1 номерлы Тәмәй авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге Уставы нигезендә Мәмәшир авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елның 26 декабренә 9 сәгать 00 минутка , «Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлегенең Тәмәй авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 25 ноябрендәге 1 номерлы Тәмәй авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлегенең Мәмәшир авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 25 ноябрендәге 1 номерлы Тәмәй авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:
- 2 пунктта:
а) беренче абзацта " 1000 сум» сүзләрен «1500 сум»сүзләренә алмаштырырга

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Мәмәшир авыл җирлеге башлыгы: И.Г.Әхмәтҗанов

СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «МАМАШИРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КУКМОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН» ОГРН 1021607753012 ИНН 1623001702